ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.07.2017 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1939**

«Бело-Безводный авылында блоклы-модульле котельный» сатып алу бурычын каплауга субсидия бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 06 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 1998 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексы» 145-ФЗ номерлы Федераль законның 78 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан «Бело-Безводный авылында блоклы-модульле котельный» сатып алу бурычын каплауга субсидия бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. «ЗМР финанс-бюджет палатасы» МУ Зеленодольск муниципаль районы бюджетында тиешле максатларга каралган акчалар чикләрендә һәм тиешле финанс елына чараларны финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017 елның 13 июлендәге 1939 номерлы карарына
Кушымта

# Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан «Бело-Безводный авылында блоклы-модульле котельный» сатып алу бурычын каплауга субсидия бирү тәртибе турында НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районында урнашкан «Бело-Безводный авылында блоклы-модульле котельный» сатып алу буенча бурычларны каплауга субсидия бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү күләме һәм шартлары процедурасын регламентлаштыра.

1.2. «Бело-Безводный авылында блоклы-модульле котельный»сатып алу бурычын каплауга субсидия Зеленодольск муниципаль районы территориясендә теркәлгән лизинг алучыларга- юридик затларга бирелә.

1.3. Субсидия бирү бушлай һәм кире кайтарылмый торган нигездә гамәлгә ашырыла һәм максатчан характерга ия.

1.4. Субсидия_______________________________________________________________ _____ карар нигезендә бирелә.

1.5. Субсидия бирүгә вәкаләтле орган (алга таба - вәкаләтле орган) булып Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

## 2. Субсидия бирү максатлары һәм субсидияләр алу хокукына ия затларны сайлап алу критерийлары

2.1. Субсидия «Бело-Безводный авылында блоклы-модульле котельный»ны сатып алу буенча бурычларны каплауга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә бушлай һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә.

2.2. Юридик затларны - лизинг алучыларны сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә юридик зат буларак билгеләнгән тәртиптә теркәлү;
- дәгъвачыларның икътисади эшчәнлекне бетерү, туктатып тору яки банкротлык стадиясендә булмавы;
- бюджетның барлык дәрәҗәләренә йөкләмәләр буенча вакыты чыккан бурыч булмау.

## 3. Субсидия бирү шартлары

Субсидия бирү шарты булып түбәндәгеләр тора:
- финанс лизингы шартнамәсе;
- бурычның булуын раслый торган тикшерү акты.

## .4. Субсидия бирү тәртибе

4.1. Субсидия алу өчен Зеленодольск муниципаль районы территориясендә теркәлгән юридик затлар - лизинг алучылар Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

- субсидия бирүгә гариза;

уставның күчермәсен;

- салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

- юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен;

- юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

- бюджет алдында бурыч булмау турында белешмә;

- финанс арендасы шартнамәсенең күчермәсен;

- бирелгән документларда белешмәләрнең дөреслеген тикшерү турында ризалык.

Гаризага мөрәҗәгать итүченең төп нөсхәләр яисә имзасы һәм мөһере белән таныкланган күчермәләр кушымта итеп бирелә.

4.2. Субсидия алу хокукына ия дәгъвачыларны сайлап алуны, тиешле карар чыгарып, Вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

4.3. Субсидия бирүдән кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән субсидия алучылар категорияләренә һәм (яисә) әлеге Нигезләмәнең 2.1, 2.2 пунктларында күрсәтелгән субсидияләр бирү өчен затларны сайлап алу максатларына һәм критерийларына туры килмәве;

- мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында каралган документларны тапшырмау;

- 4.1 пунктында каралган документлар тулы күләмдә күрсәтелмәгән һәм техник хаталарны үз эченә ала (Нигезләмә максатлары өчен документны рәсмиләштерү процессында документка кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр нигезендә кертелгән документлардагы белешмәләрнең туры килмәвенә китергән, зат тарафыннан җибәрелгән язу, хәреф хатасы, лексик, орфографик яисә арифметик хата яисә шуңа охшаш хата техник хаталар дип таныла);

- әлеге Нигезләмәнең 4.1 пункты нигезендә каралган документлар гамәлдәге законнар таләпләренә туры килми.

4.4. Субсидия алучыларга, РФ БК 78 статьясының 5.1 өлешенә ярашлы рәвештә, алынган акчалар, чит ил валютасы хисабына, Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) башкарыла торган операцияләрдән тыш, шулай ук күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар

белән әлеге чараларны башка операцияләр белән тәэмин итү максатларына ирешү белән бәйле рәвештә, сатып алу тыела.

4.5. Субсидия бирүнең нигезе булып субсидия алучы белән Вәкаләтле орган арасында законнар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә төзелгән Субсидия бирү турында килешү тора.

4.6. Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- субсидия алу хокукына ия булган юридик затларны - лизинг алучыларны сайлап алу категорияләре һәм (яисә) критерийлары;

- субсидия күләме турында белешмәләр;

- субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе;

- субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта тиешле бюджетка субсидияне кайтару тәртибе;

- агымдагы финанс елында субсидия алучыга Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда хисап финанс елында кулланылмаган субсидия өлешләрен кире кайтару тәртибе;

- субсидия бирә торган бюджет акчаларының баш бүлүче (күрсәтмә бирүче) һәм субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүне дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы тарафыннан мәҗбүри тикшерү турында нигезләмәләр.

4.7. Субсидия алучылар әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында каралган документларда бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен гамәлдәге законнарда каралган тулы җаваплылыкны үз өстенә ала.

4.8. Субсидия күчерү субсидия алучының исәп-хисап счетына гамәлгә ашырыла.

## 5. Субсидияне кире кайтару тәртибе

5.1. Субсидия алучы субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозган очракта, Вәкаләтле орган күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турында хәбәрнамә җибәрә.

5.2. Әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән шартлар ачыкланганда, субсидия алучы субсидияне Зеленодольск муниципаль районы бюджетына мөстәкыйль рәвештә яки Вәкаләтле орган таләбе буенча кире кайтара.

5.3. Субсидияне кире кайтару субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турындагы таләпне җиткергәннән соң җиде банк көне эчендә башкарыла, әмма агымдагы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

5.4. Субсидияләрне кире кайтару хәбәрнамәдә күрсәтелгән Россия Федерациясе бюджетлары керемнәре классификациясенең реквизитлары һәм коды буенча гамәлгә ашырыла.

5.5. Әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктын үтәмәгәндә, алынмаган сумма түләнеп бетмәгән өлеше булып санала һәм үз вакытында түләмәгән һәр көн өчен 0,01% күләмендә пенялар исәпләнә.

5.6. Хисап финанс елында алучының файдаланылмаган субсидиясе яисә аның өлеше 5.3 һәм 5.4 пунктлары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

5.7. Субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартларны бозып кулланылган акчаларны субсидия кире кайтармаган яки ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, түләтү Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә башкарыла.

## 6. Субсидия бирүнең һәм аннан файдалануның шартларын, максатларын, тәртибен үтәүне контрольдә тоту

6.1. Субсидия бирүче бюджет акчаларының Баш бүлүчесе (күрсәтмә бирүчесе) һәм муниципаль финанс контроле органы (МУ «ЗМР Контроль-хисап палатасы») билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне мәҗбүри тикшерә.

6.2. Вәкаләтле орган субсидияләр бирү турында төзелгән килешү шартларының тиешенчә үтәлешен һәм хисапларны вакытында бирүне контрольдә тота.